ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЛАН-БӘКСӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422723, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Алан-Бексәр авылы, Үзәк ур., 19

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛАН-БЕКСЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422723, Татарстан Республикасы, Высокогорский район,
с.Алан-Бәксер, ул.Центральная, 19

тел./факс 8(84365) 63-9-51, e-mail: AlanB.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
26.05.2020 ел

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
№22

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын комплексلы үстерү Программасын раслау турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары" Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 номерлы "Җирлекләр, шәһәр округлары транспорт инфраструктурасы системасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турындагы" Карары, Алан-Бәксәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндә китерелгән кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү Программасын расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылып чыгарганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе З.Р.Гарифуллина

Кушымта

Расланды
Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Советының 2020 елның 26 маендагы 22 нче номерлы Карары белән

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫ

## ЭЧТӘЛЕК

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ПАСПОРТЫ

**I БҮЛЕК. Алан-Бәксәр авыл җирлегендә транспорт инфраструктурасының гамәлдәге торышы характеристикасы.**

1.1 Россия Федерациясенең пространство оешмасы структурасында Татарстан Республикасы торышына анализ, Татарстан Республикасы пространство оешмасы структурасында Биектау муниципаль районының торышына анализ, Татарстан Республикасы пространство оешмасы структурасында Алан-Бәксәр авыл җирлегенең торышына анализ

1.1.1 Россия Федерациясенең пространство оешмасы структурасында Татарстан Республикасы торышына анализ

1.1.2 Татарстан Республикасы пространство оешмасы структурасында Биектау муниципаль районының торышына анализ

1.1.3 Татарстан Республикасының пространство оешмасы структурасында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Биектау авыл җирлеге торышына анализ

1.2 Биектау районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең социаль-икътисадый характеристикасы, авыл җирлеге территориясендәге, транспорт өлкәсендәге эшчәнлекне, транспортка сорауны да кертеп, шәһәр төзелеше эшчәнлегенә характеристика

1.3 Функция башкару һәм транспорт төрләре буенча транспорт инфраструктурасы эше күрсәткечләре характеристикасы

1.4 Алан-Бәксәр авыл җирлеге юллары челтәренең характеристикасы, юл хәрәкәте параметрлары (транспорт чаралары хәрәкәте агымының тизлеге, тыгызлыгы, интенсивлыгы)

1.5 Транспорт чаралары паркы составына һәм автомобильләштерү дәрәҗәсенә анализ, парковкалар белән тәэмин ителеш (парковка урыннары белән)

1.6 Гомуми кулланылыштагы транспорт чараларының эшчәнлегенә, пассажир агымы анализын да кертеп, характеристика

1.7 Җәяүлеләр һәм велосипед хәрәкәте шартларына характеристика

1.8 Йөк транспорты чаралары хәрәкәтенә характеристика, Көнкүреш һәм юл хезмәте транспорт чаралары эшен бәяләү, әлеге транспорт чаралары өчен инфраструктура торышы

1.9 Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәрәҗәсенә анализ

1.10 Транспорт инфраструктурасының әйләнә-тирә мохиткә, халыкның иминлегенә һәм сәламәтлегенә начар йогынтысы дәрәҗәсен бәяләү

1.11 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасының гамәлдәге шартларына һәм үсеш перспективаларына һәм урнаштырылуына характеристика

1.12 Алан-Бәксәр авыл җирлеге транспорт инфраструктурасының эшчәнлегенә һәм үсешенә кирәкле норматив-хокукый базаны бәяләү

1.13 Транспорт инфраструктурасын финанслауны бәяләү

**II БҮЛЕК. Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә транспорт ихтыяҗына, халык хәрәкәте һәм йөк ташу күләме һәм характеры үзгәрүгә фараз**

2.1 Социаль-икътисади үсешкә фараз

2.2 Биектау районы транспорт инфраструктурасы үсешенә фараз

2.3 Урам-юл челтәре үсешенә фараз

2.4 Автомобильләштерү дәрәҗәсенә, юл үсеше параметрларына, парковкалау пространствосына ихтыяҗга фараз

2.5 Юл хәрәкәте иминлеге күрсәткечләренә фараз

2.6 Транспорт инфраструктурасының әйләнә-тирә мохиткә, халыкның иминлегенә һәм сәламәтлегенә начар йогынтысына фараз

**III БҮЛЕК. Транспорт инфраструктурасын үстерүнең принципиаль вариантлары һәм аларны транспорт инфраструктурасы үсешенең максатчан күрсәткечләре буенча (индикаторлары буенча), үз чиратында тормышка ашыруга тәкъдим ителгән вариантын сайлау белән, эреләндереп бәяләү**

3.1 Транспорт инфраструктурасының гамәлдәге торышын яки Программаны тормышка ашыру чорында транспорт инфраструктурасы торышы күрсәткечләре

3.2 Транспорт инфрастрктурасын үстерүнең принципиаль вариантларын эреләндереп бәяләүне үткәрү һәм тормышка ашыруга тәкъдим ителгән вариантны сайлау

**IV БҮЛЕК. Транспорт инфраструктурасын үстерүне тормышка ашыруга тәкъдим ителгән вариантның транспорт инфраструктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча чараларын финанслау (инвестиция проектлары) күләмнәрен һәм чыганакларын бәяләү**

4.1 Транспорт инфраструктурасының транспорт төрләре буенча үсеше

4.2 Гомуми кулланышлы пассажир автомобиль транспортын үстерү, транспорт-күчеп утыру урыннарын ясау буенча чаралар

4.3 Җиңел автомобиль транспорты өчен, бердәм парковкалау пространствосын үстерүне дә кертеп, инфраструктураны үстерү

4.4 Җәяүлеләр һәм велосипед хәрәкәте инфраструктурасын үстерү

4.5 Йөк транспорты, көнкүреш һәм юл хезмәте транспорт чаралары өчен инфраструктура үстерү

4.6 Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге юл челтәрен үстерү

**V БҮЛЕК. Транспорт инфраструктурасын үстерүне тормышка ашыруга тәкъдим ителгән вариантның транспорт инфраструктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча чараларын финанслау (инвестиция проектлары) күләмнәрен һәм чыганакларын бәяләү**

**VI БҮЛЕК. Транспорт инфраструктурасын үстерүне тормышка ашыруга тәкъдим ителгән вариантның транспорт инфраструктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча чараларының (инвестиция проектлары) нәтиҗәлелеген бәяләү**

**VII БҮЛЕК. Транспорт инфрастрктурасы объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү өлкәсендә эшчәнлекне хокукый һәм мәгълүмати тәэмин итүне, институциональ үзгәртеп коруларны камилләштерү буенча тәкъдимнәр**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЛАН-БӘКСӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ТРАНСПОРТ ИНФРАСТРУКТУРАСЫН КОМПЛЕКСЛЫ ҮСТЕРҮ ПРОГРАММАСЫНЫҢ ПАСПОРТЫ**

| | |
|---|---|
| Программа исеме | 2019-2028 елларга Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү Программасы (алга таба – Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | - 2004 елның 29 декабрендәге 191-ФЗ номерлы “Россия Федерациясенең Шәһәр төзелеше кодексын гамәлгә кертү турындагы” Федераль законы;<br>- 2003 елның 6 октябреннән 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары” Федераль законы;<br>- 2007 елның 9 февраленнән 16-ФЗ номерлы “Транспорт куркынычсызлыгы турында” Федераль законы;<br>- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге 1440 нчы номерлы “Җирлекләр, шәһәр округлары транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларына таләпләрне раслау турындагы” Карары. |
| Программаның Заказчысы | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 |
| Программаны эшләүче | Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге Башкарма комитеты, Биектау районы, Алан-Бәксәр авылы, Үзәк ур., 19 |
| Программаның максатлары | Алан-Бәксәр авыл җирлегенең заманча һәм нәтиҗәле транспорт инфраструктурасын үстерү, хәрәкәт иминлеге дәрәҗәсен күтәрү, муниципаль берәмлек халкы өчен транспорт комплексы хезмәтләреннән файдалану мөмкинлеген һәм сыйфатын күтәрү. |
| Программаның бурычлары | 1) халыкка, шулай ук җирлек территориясендә эшчәнлекләрен гамәлгә ашыручы юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә транспорт хезмәте күрсәтүнең куркынычсызлыгы, сыйфаты, нәтиҗәлелеге;<br>2) җирлекне проектлауның шәһәр төзелеше нормативлары нигезендә транспорт инфраструктурасы объектларының халыкка һәм икътисадый эшчәнлек субъектларына файдалану мөмкинлеге; |

| | |
|---|---|
| | 3) халыкның хәрәкәткә, икътисадый эшчәнлек субъектларына – җирлек территориясендә пассажирларны һәм йөк ташуга ихтыяҗлары нигезендә транспорт инфраструктурасын үстерү;<br>4) җирлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеге белән балансланган транспорт инфраструктурасын үстерү;<br>5) транспортка сорау белән идарә итүгә шартлар;<br>6) хуҗалык эшчәнлегенең икътисадый нәтиҗәләренә карата юл хәрәкәтендә катнашучыларының тормышы һәм сәламәтлеге куркынычсызлыгын тәэмин итүгә өстенлекле шартлар тудыру;<br>7) гомуми кулланылыштагы транспорт чаралары хәрәкәтенә башка транспорт чараларына карата өстенлекле шартлар тудыру;<br>8) халыкның җәяү һәм велосипедта йөрүенә шартлар;<br>9) гамәлдәге транспорт инфраструктурасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге. |
| Транспорт инфраструктурасын үстерүнең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары) | -Гомуми файдаланудагы каты өслекле юлларның озынлыгы, (км);<br>- ГОСТ һәм СНИП таләпләренә җавап биргән тротуарларның озынлыгы;<br>- авыл җирлегенең транспорт-эксплуатацияләү норматив таләпләренә җавап биргән юл челтәре озынлыгының өлеше (%);<br>- теркәлгән юл хәрәкәте фаҗигаләренең саны;<br>яңа җиһазланган машина-урыннар саны. |
| Транспорт инфраструктурасы объектларын (чаралар төркемнәре, ярдәмче программалар, инвестиция проектлары) проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларны (инвестиция проектларын) эреләндерелгән тасвирлама | Әлеге программада тасвирланган чаралар транспорт чараларын файдаланучыларнның, җәяүлеләрнең уңайлылыгы һәм куркынычсызлыгы дәрәҗәсен күтәрүгә һәм авыл җирлегенең социаль-икътисади хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән |
| Прогарамманы тормышка ашыруның | Программа 2018 елдан 10 ел дәвамында 2 этапта тормышка ашырыла: |

<table>
<tr><td>сроклары һәм этаплары</td><td colspan="6">I этап: 2019 елдан 2023 елга кадәр.<br>II этап: 2024 елдан 2028 елга кадәр.</td></tr>
<tr><td>Программаның төп чаралары</td><td colspan="6">1. Җирлекнең транспорт инфраструктурасы хәлен яхшыртуга юнәлдерелгән эшләрне башкару.<br>2. Юл хәрәкәте иминлеген күтәрүгә юнәлдерелгән эшләрне башкару.<br>3. Транспорт инфраструктурасы объектларын реконструкцияләү буенча чаралар.<br>4. Транспорт инфраструктурасы объектларын төзү буенча чаралар.</td></tr>
<tr><td rowspan="12">Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td colspan="2">Сроклары, чор</td><td colspan="4">Программаны тормышка ашыру өчен кирәкле финанслау, мең сум.</td></tr>
<tr><td colspan="2">2019 ел</td><td colspan="4">650</td></tr>
<tr><td colspan="2">2020 ел</td><td colspan="4">650</td></tr>
<tr><td colspan="2">2021 ел</td><td colspan="4">650</td></tr>
<tr><td colspan="2">2022 ел</td><td colspan="4">650</td></tr>
<tr><td colspan="2">2023 ел</td><td colspan="4">650</td></tr>
<tr><td colspan="2">2024-2028 еллар</td><td colspan="4">3250</td></tr>
<tr><td colspan="6">Финанслау чыганаклары, мең сум.</td></tr>
<tr><td>Чор</td><td colspan="2">Җирле бюджет</td><td>Төбәк бюджеты</td><td>БТЧ</td><td>Барлыгы</td></tr>
<tr><td>2019-2023 еллар</td><td colspan="2">750</td><td>1250</td><td>1250</td><td>3250</td></tr>
<tr><td>2024-2028 еллар</td><td colspan="2">750</td><td>1250</td><td>1250</td><td>3250</td></tr>
<tr><td>Барлыгы</td><td colspan="2">1500</td><td>2500</td><td>2500</td><td>6 500</td></tr>
</table>

## I БҮЛЕК. Биектау муниципаль районы Алан-Бәксәр авыл җирлеге транспорт инфраструктурасының хәзерге торышына характеристика

1.1 Россия Федерациясенең пространство оешмасы структурасында Татарстан Республикасы торышына анализ, Татарстан Республикасы пространство оешмасы структурасында Биектау муниципаль районының торышына анализ, Татарстан Республикасы пространство оешмасы структурасында Алан-Бәксәр авыл җирлегенең торышына анализ

1.1.1. Россия Федерациясенең пространство оешмасы структурасында Татарстан Республикасы торышына анализ.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең субъекты булып тора һәм Идел буе Федераль округы составына керә, шулай ук Идел буе икътисади районына карый. Республиканың административ һәм мәдәни үзәге – Казан шәһәре. Татарстан Көнчыгыш Европа тигезлегенең көнчыгышында, ике иң эре елга – Идел һәм Кама кушылган урында урнашкан, Казан шәһәре Мәскәү шәһәреннән көнчыгышка таба 797 км ераклыкта урнашкан. Татарстан Республикасы 1920 нче елда төзелә. Мәйданы 6783,7 мең га. Территориянең максималь озынлыгы – төньяктан көньякка таба 290 км һәм көнбатыштан көнчыгышка таба 460 км. Татарстан чит илләр белән чикләшми. Көньяктан Татарстан Республикасы Самара, Ульяновск һәм Оренбург өлкәләре белән, төньяктан – Киров өлкәсе һәм Удмурт Республикасы, төньяк-көнчыгыштан – Марий Эл Республикасы, көнчыгыштан – Башкортостан Республикасы, көнбатыштан – Чуваш Республикасы белән чиктәш.

Республика территориясендә 43 муниципаль район, 2 шәһәр округы, 39 шәһәр һәм 872 авыл җирлеге урнашкан.

Татарстан территориясе куе елгалар челтәре белән бүлгәләнгән баскычлы калкулыклы тигезлекне барлыкка китерә. Идел һәм Каманың киң үзәннәре белән тигезлек өч өлешкә бүленә: Идел алды, Кама алды һәм Кама аръягы. Идел алды Идел буе калкулыкларының максималь биеклеге 276 м булган төньяк-көнчыгыш өлешен алып тора. Көнчыгыш Кама алдына төньяктан Можга һәм Сарапул калкулыкларының Иж елгасы белән бүленгән көньяк кушымталары килеп тоташа. Монда иң биек калкулык 243 м га җитә. Татарстанда иң биек (381 м га кадәр) булып Көнчыгыш Кама аръягындагы Бөгелмә калкулыгы санала. Иң түбән рельеф ( нигездә 200 м га кадәр) Көнбатыш Кама аръягына хас. Татарстанның якынча 17% территориясе урманнар белән капланган, алар күбрәк киң яфраклы агачлардан тора (имән, юкә, каен, усак), ылыслы төр агачлар нарат һәм чыршы белән сыйфатлана. Татарстан территориясендә 433 төр умырткалылар, шулай ук берничә мең төр умырткасыз хайваннар яши.

Татарстан территориясе җылы җәйле һәм уртача-салкын кышлы урта киңлекнең уртача-континенталь климат тибы белән сыйфатлана. Иң җылы җәй ае территориянең уртача айлык температурасы 18-20 °С ны тәшкил иткән июль ае, иң салкын ай – январь, уртача айлык температура -13 °С. Җылы вакытның дәвамлылыгы (0 °С тан югары температуралы) 198-209 көн тирәсендә тирбәлә, салкын чор – 156-167 көн тирәсендә. Территория буенча явым-төшем якынча тигез бүленә, якынча еллык суммасы 460-540 мм тәшкил итә.

Туфрагы төрлелек белән аерыла: төньякта һәм көнбатышта соры урман һәм көлсыманнан алып, республиканың көньягында кара туфракның төрле төрләренә кадәр.

Татарстан территориясендә Идел-Кама дәүләт табигый биосфера тыюлыгы һәм “Түбән Кама” милли паркы урнашкан.

Татарстан – икътисад буенча Россиянең иң алга киткән регионнарыннан берсе. Республика Россия Федерациясенең эре индустриаль районы үзәгендә, көнчыгыш һәм көнбатышны, төньяк һәм көньякны тоташтыручы магистральләр кисешүендә урнашкан.

Татарстан Республикасы бай табигый ресурсларга, көчле һәм

диверсификацияле сәнәгатькә, югары интеллектуаль һәм квалификацияле эшче көченә ия.

Татарстан Республикасы төп макроэкономика күрсәткечләре буенча Россия Федерациясенең алдынгы регионнары исәбенә керә.

Татарстанның тулаем региональ продукты структурасында сәнәгать өлеше 43,2 %, төзелеш – 9,0 %, транспорт һәм элемтә – 6,5 %, авыл хуҗалыгы – 7,5% алып тора.

Республиканың сәнәгать профилен нефть-газ химиясе комплексы (нефть чыгару, синтетик каучук, шиннар, полиэтилен һәм нефть эшкәртү продуктларының киң спектрын җитештерү), конкурентлыкка сәләтле продукция җитештерүче эре машина төзү предприятиеләре (авыр йөк машиналары, вертолётлар, самолетлар һәм авиадвигательләр, компрессорлар һәм нефть-газ кудыру җиһазлары, елга һәм диңгез суднолары, коммерцияле һәм җиңел автомобиль төрләре), шулай ук алга киткән электр- һәм радиоприборлар җитештерү билгели.

Татарстанда сәнәгать җитештерүе индексы 2018 ел нәтиҗәләре буенча 102% ка җитте. Республиканың сәнәгать җитештерүе күләме 2 трлн 818 млрд сум тәшкил итте.

ТР ның сәнәгать секторында мәшгуль халыкның урта исемлек саны 2018 нче елның гыйнвареннән ноябренә кадәр 336,8 мең кешене тәшкил итә, сәүдә өлкәсендә 148,6 мең кеше мәшгуль.

Тулаем региональ продуктта сәнәгать өлеше 44,6%, сәүдә - 16,4% ны тәшкил итә. Сәүдә өлкәсе республиканың ТРПнә кертеме буенча динамик үсештәге өлкәләрнең берсе булып кала.

Татарстан Идел буе федераль округы регионнары арасында лидерлык позицияләрен алып тора. 2018 нче ел нәтиҗәсе булып республика сәүдәсендә ваклап сату әйләнеше үсешенең 2017 нче ел күрсәткечләренә карата 106,1% дәрәҗәсенә җитүе тора.

Узган елда республика сәүдә өлкәсенең структурасы үзгәрде. Азык-төлек товарлары өлеше 47% тан 44 % ка кадәр кимеде, шул ук вакытта озак кулланылышлы товарлар өлеше арткан. Ваклап сату базарларының сату күләмнәре үсә, хәзер бу күрсәткеч 7 % ка җитте. Шул ук вакытта республикада челтәрле сату башка регионнар белән чагыштырганда әзрәк үскән.

1.1.2. Татарстан Республикасының пространстволы оештырылуында Биектау муниципаль районының тоткан урынына анализ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының административ үзәге булып 3 мең халкы булган Биектау тимер юл станциясе бистәсе тора. Биектау станциясе район үзәге булып юкка гына билгеләнмәде. Тимер юл һәм "Себер Тракты" шоссесы аны Казан белән бәйләде, юллар район территориясен ике тигез өлешкә бүлде һәм Биектау аларның үзәгендә иде.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы республиканың төньяк-көнбатыш өлешендә урнашкан һәм Казан шәһәре, Яшел үзән, Арча, Әтнә, Питрәч районнары һәм Мари-Эл Республикасы җирләре белән чиктәш. Бөек Габдулла Тукай тарафыннан җырланган Казан арты нәкъ менә шушында башлана.

Без Татарстан Республикасының 43 административ районының берсендә - Биектауда яшибез. Аның мәйданы 1574,78 кв.км тәшкил итә. Биектау районы

барлыкка килүнең рәсми датасы булып 1935 елның 25 январе санала. Безнең район - Татарстан Республикасында халык мәйданы һәм саны буенча иң эреләрнең берсе. Аның территориясендә 123 торак пунктны берләштерүче 28 авыл җирлеге советы эшли. Биредә төрле милләттәге 43,6 мең кеше, шулардан татарлар 64 %, руслар - 34 % һәм 2 %ы - башка милләт вәкилләре дус һәм тату яши. Татарстан Республикасының Биектау районы Урта Иделнең иң борынгы мәдәни һәм рухи районнарыннан берсе буларак билгеле. Нәкъ менә шушы җирләрдә XII-XIV йөзләрдә легендар «Иске Казан» урнашкан була, хәзер анда археологик музей-тыюлык эшли.

Биектау муниципаль районы Казан шәһәреннән автомобиль юлларының төбәк һәм федераль челтәре буенча 10-15 минутлык ераклыкта урнашкан.

Биектау районы, Татарстан Республикасы кебек үк, уртача климат поясының уртача континенталь климаты өлкәсендә урнашкан. Гомумән алганда, климатны уртача континенталь, җылы җәй һәм уртача-салкын кыш дип сыйфатларга була. Төп климат характеристикалары түбәндәгечә күренә:

июльнең уртача температурасы: 18,5° – 19,5°
январьнең уртача температурасы: -14,5° – -13,5°
елның җәйге вакытында явым-төшемнәр: 320 – 340 мм
елның кышкы вакытында явым-төшемнәр: 160 – 180 мм
еллык явым-төшемнәр суммасы: 460 – 520 мм
кар катламы биеклеге: 35 – 50 см
җил юнәлешенең өстенлек итүче юнәлеше: көнбатыш, төньяк-көнбатыш.

Территориянең эчке сулары - елгалар, күлләр, җир асты сулары, сазлыклар, бозлыклар. Безнең районда халыкны һәм хуҗалыкларны су белән тәэмин итүдә елгалар, күлләр һәм җир асты сулары аеруча мөһим роль уйный.

Территориянең эчке сулары - елгалар, күлләр, җир асты сулары, сазлыклар, бозлыклар. Безнең районда халыкны һәм хуҗалыкларны су белән тәэмин итүдә елгалар, күлләр һәм җир асты сулары аеруча мөһим роль уйный.

Биектау районының иң зур елгалары - Казансу һәм Ашыт елгалары. Казансу Татарстан Республикасының Арча районында башлана, урта агымында Биектау районы аша уза һәм Казан шәһәре чигендә Идел елгасына коя. Ашыт Татарстан Республикасының Әтнә районында башлана һәм Татарстан Республикасының Биектау районы һәм Мари-Эл Республикасы чигендә һәм Иләт елгасына коя.

Районда 138 күл бар. Карасу, Кара Күл, Мунчалалы иң эреләре. Бу күлләрнең барысында да табигать һәйкәлләре статусы бар. Аларның кайбер характеристикалары таблицада китерелгән.

Биектау районының Татарстан Республикасы территориясендә урнашуы 1 нче рәсемдә күрсәтелгән.




Биектау районында - 25 авыл җирлеге, алар үзләренә 124 торак пунктны алалар – аларның исемлеге 1 нче таблицада китерелгән.

1 нче таблица - Муниципаль берәмлек территориясе составына керә торган торак пунктлар

| N т/б | Муниципаль берәмлек | Администрация үзәге | Торак пунктлар саны |
|---|---|---|---|
| Авыл җирлекләре | | | |
| 1 | Айбаш авыл җирлеге | Айбаш авылы | 6 |
| 2 | Алан-Бәксәр авыл җирлеге | Алан-Бәксәр авылы | 5 |
| 3 | Әлдермеш авыл җирлеге | Әлдермеш авылы | 3 |
| 4 | Каенлык авыл җирлеге | Каенлык авылы | 12 |
| 5 | Олы Кавал авыл җирлеге | Олы Кавал авылы | 4 |
| 6 | Олы Битаман авыл җирлеге | Олы Битаман авылы | 4 |
| 7 | Бөреле авыл җирлеге | Бөреле җәнлек совхозы бистәсе | 6 |
| 8 | Биектау авыл җирлеге | Биектау авылы | 7 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | Дачный авыл җирлеге | Дачный бистәсе | 2 |
| 10 | Дөбъяз авыл җирлеге | Дөбьяз авылы | 6 |
| 11 | Иске-Казан авыл җирлеге | Коркачык авылы | 7 |
| 12 | Казаклар авыл җирлеге | Казаклар авылы | 4 |
| 13 | Красносельский авыл җирлеге | Биектау тимер юл станциясе бистәсе | 6 |
| 14 | Коркачык авыл җирлеге | Коркачык тимер юл разъезды бистәсе | 1 |
| 15 | Мәмдәл авыл җирлеге | Мәмдәл авылы | 2 |
| 16 | Мүлмә авыл җирлеге | Мүлмә авылы | 5 |
| 17 | Семиозерка авыл җирлеге | Семиозерка авылы | 6 |
| 18 | Алат авыл җирлеге | Алат авылы авылы | 4 |
| 19 | Суыксу авыл җирлеге | Суыксу авылы | 6 |
| 20 | Ташлы-Кавал авыл җирлеге | Ташлы-Кавал авылы | 5 |
| 21 | Усад авыл җирлеге | Усад авылы | 7 |
| 22 | Чыпчык авыл җирлеге | Чыпчык авылы | 4 |
| 23 | Чернышевка авыл җирлеге | Чернышевка авылы | 6 |
| 24 | Шәпше авыл җирлеге | Шәпше авылы | 3 |
| 25 | Ямаширмә авыл җирлеге | Ямаширмә авылы | 3 |

Муниципаль район җирле үзидарә органнары структурасын түбәндәгеләр барлыкка китерә:
- депутатлар Советы;
- муниципаль район Башлыгы;
- “Биектау районы” муниципаль берәмлеге Администрациясе;
- муниципаль районның контроль органы;
- муниципаль район Башлыгы тәкъдиме буенча депутатлар Советы карары белән гамәлгә куела торган һәм юридик зат хокукларына ия башка җирле үзидарә органнары.

1.1.3 Татарстан Республикасының пространство оешмасы структурасында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлеге торышына анализ.

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Алан-Бәксәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге бердәм икътисадый, тарихи, социаль, территориаль берәмлек булып тора, "Биектау районы" муниципаль берәмлеге составына керә.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге "Биектау муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турындагы" 2005 елның 31 январендагы 20-ТРЗ номерлы (30.12.2014 ред.) Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге составына бу закон нигезендә керәләр: Алан-Бәксәр авылы (административ үзәк), Алат спиртзаводы авылы, Гәр авылы, Әсән авылы, Шөмлән авылы.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге Татарстан Республикасының төньяк-көнбатыш өлешендә, Биектау муниципаль районының төньяк өлешендә урнашкан. Алан-Бәксәр авыл җирлеге Мари-Эл Республикасы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алат, Казаклар, Дөбьяз, Олы Битаман, Суыксу авыл җирлекләре белән чиктәш.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең гомуми мәйданы 4490 га га, шул исәптән торак пунктлар мәйданы 1467,9 мең кв.м., алардан: Алан-Бәксәр авылы -446,8 мең кв.м., Алат спиртзаводы авылы –322,2 мең кв. м., Гәр авылы-368,5 мең кв. м., Әсән авылы -199,7 мең кв. м., Шөмлән авылы - 130,0 мең кв.м.

Урман фонды җирләре 840 гектар мәйданны били, бу авыл җирлегенең бөтен мәйданыннан 18,7 % чамасын тәшкил итә (картографик материал буенча).

Биектау муниципаль районының гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының гамәлдәге челтәре радиаль-хорд структурасына ия һәм региональ һәм җирле әһәмияттәге юллар белән тәкъдим ителә.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Татарстан Республикасының башка районнары белән транспорт элемтәсе хәзерге вакытта муниципальара әһәмияттәге региональ автомобиль юллары һәм җирле әһәмияттәге юллар аша гамәлгә ашырыла.

Тулаем Биектау районының да, Алан-Бәксәр авыл җирлегенең дә икътисадый-географик хәле шактый отышлы, дияргә була. Татарстан Республикасының төньяк-көнбатышында һәм Биектау районының төньяк өлешендә Алан-Бәксәр авыл җирлегендә Татарстан Республикасының район үзәге һәм башка районнары белән транспорт элемтәләрен гамәлгә ашыру уңайлы һәм ресурслар белән җитәрлек тәэмин ителешле (руда булмаган файдалы казылмалар, урман, су һәм җир ресурслары).

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Биектау муниципаль районы җирлеге территориясендә урнашуы 2 нче рәсемдә күрсәтелгән.

2 нче рәсем
Алан-Бәксәр авыл җирлегенең
Биектау муниципаль районы
территориясендә урнашуы




## 1.2 Биектау районы Алан-Бәксәр авыл җирлегенең социаль-икътисади характеристикасы, авыл җирлеге территориясендә шәһәр төзелеше эшчәнлегенә характеристика, транспорт өлкәсендәге эшчәнлекне дә кертеп, транспорт ихтыяҗын бәяләү

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Алан-Бәксәр авыл җирлегендә 2019 елның 1 январена 609 кеше яши. Авыл халкы 100 % тәшкил итә.

2 нче Таблицада авыл җирлегендә 2019 елның 1 январена елларга торак пунктлар буенча халыкның бүленеше тәкъдим ителгән.

2 нче таблица - торак пунктлар буенча халык саны

| N т/б | Торак пункт | Халык саны, кеше. |
|---|---|---|
| 1 | Алан-Бәксәр | 337 |
| 2 | Алат спиртзаводы авылы | 109 |
| 3 | Гәр авылы | 156 |
| 4 | Әсән авылы | 3 |
| 5 | Шөмлән авылы | 4 |

2017 елдан Алан-Бәксәр авыл җирлегендә халык саны үзгәрешсез кала һәм 609 кеше тәшкил итә. Таблицадан күренгәнчә, җирлекнең иң зур торак пункты булып Алан-Бәксәр авылы тора, анда халыкның күпчелек өлеше яши - 55,3%.

Биектау муниципаль районының 25 авыл җирлеге арасында Алан-Бәксәр авыл халкы саны буенча 22 нче урында.

Хезмәткә сәләтле яшьтәге халык (ир-атлар да, хатын-кызлар да) үлеменең төп сәбәпләре - йөрәк-кан тамырлары авырулары. Соңгы өч елда халыкның миграцион кимүе күзәтелми. 2012 елда авыл җирлегенә инвестор килү белән эш урыннары җитмәү проблемасы хәл ителде.

Соңгы 10 елда халыкның читкә китүе, бигрәк тә яшь буынның, белгечлек алганнан соң шәһәрдә өйләренә ашыкмаулары, авыл җирендә яшәргә теләмәүләре белән аңлатыла. Район Казанның шәһәр яны, һәм яшьләрне Казандагы тормыш һәм эш җәлеп итә. Вәзгыятьне үзгәртү өчен авыл җирлегенең инвестицион җәлеп итүчәнлеген күтәрү зарур.

Халык санын тотрыклы итүнең төп коралы булып халыкның читкә китүен туктату һәм халыкның миграция агымын көчәйтү өчен шартлар тудыру кала. Шул ук вакытта, барган табигый процессларның туры килүен һәм миграция хәрәкәтчәнлеген исәпкә алып, авыл җирлеге территориясендә яшь буынны җәлеп итү һәм саклап калу хезмәт ресурсларын беркадәр саклап калуга һәм демографик потенциалны ерак перспективага яңартуга гына ярдәм итә ала.

Муниципаль берәмлектә демографик вәзгыятьне яхшырту өчен социаль-икътисадый чараларның тулы бер комплексын уздыру кирәк, алар демографик үсешне билгеләүче төрле аспектларга юнәлдереләчәк, ягъни үлүчеләрнең гомуми дәрәҗәсен (шул исәптән социаль әһәмияткә ия авырулардан һәм тышкы сәбәпләрдән) кыскарту, халыкның репродуктив сәламәтлеген ныгыту, балалар һәм яшүсмерләрнең сәламәтлеген ныгыту, аналар һәм сабыйлар үлеме дәрәҗәсен кимету, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, гомер озынлыгын арттыру, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен шартлар тудыру, гаилә институтын ныгыту, гаилә арасындагы ныклы мөнәсәбәтләр традицияләрен торгызу һәм саклау, аналарга һәм балаларга ярдәм итү, миграция ситуациясен яхшырту.

## 1.3 Функция башкару һәм транспорт төрләре буенча транспорт инфраструктурасы эше күрсәткечләре характеристикасы.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең транспорт системасын үстерү җирлектә яшәүчеләрнең тормыш сыйфатын яхшыртуның кирәкле шарты булып тора.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасы Татарстан Республикасы Биектау районы инфраструктурасын тәшкил итә, бу гражданнарның хәрәкәт итү ирегенә конституция гарантияләрен тәэмин итә һәм товарларның һәм хезмәтләрнең ирекле хәрәкәт итүен мөмкин итә. Автомобиль юллары челтәренең булуы һәм торышы белән территориаль бөтенлек һәм икътисадый киңлекнең бердәмлеге билгеләнә. Җирле әһәмияттәге юллар һәм инфраструктура торышының җәмгыятьнең социаль-икътисадый ихтыяҗларына туры килмәве проблемасын бәяләп бетермәү икътисадый кыенлыкларның һәм тискәре социаль процессларның сәбәпләреннән берсе булып тора.

Хәзерге вакытта Алан-Бәксәр авыл җирлегенең Татарстан Республикасының башка районнары белән транспорт элемтәсе муниципальара әһәмияттәге һәм җирле әһәмияттәге региональ автомобиль юллары аша гамәлгә ашырыла.

"Каменка – Дөбьяз – Олы Әтнә – Казан" муниципальара әһәмияттәге юл Алан-Бәксәр авыл җирлегеннән 10 км (Дөбьяз аша) уза.

" Каменка – Дөбьяз – Олы Әтнә – Казан " (V категория) юлы аның бөтен буена асфальт-бетон белән капланган.

Алат спиртзавод авылына бару юлы (V категория). Асфальт-бетон белән капланган юлның озынлыгы 2 км.

Гәр авылына бару юлы (юлның гомуми озынлыгы 12 км), 5 км (V категория) - асфальт-бетон белән капланган, 7 км (IV категории) – вак таш белән каплаулы.

Шөмлән авылына бару юлы – юлның озынлыгы 15 км, шуларның: 5 км (V категория) асфальт-бетон өслекле, 7 км (IV категория) вак таш өслекле, 3 км – балчык юл.

Әсән авылына бару юлы (IV категория). Юлның озынлыгы 3,5 км, вак таш өслекле.

Алан-Бәксәр АҖ 1 күпер корылмасы урнашкан:

- "Дөбьяз – Алан-Бәксәр – Ислейтар урман хуҗалыгы" а/юлы –Ашыт елгасы.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә АЗС лар юк.

## 1.4 Алан-Бәксәр авыл җирлеге юллары челтәренең характеристикасы, юл хәрәкәте параметрлары (транспорт чаралары хәрәкәте агымының тизлеге, тыгызлыгы, интенсивлыгы)

Автомобиль юллары Алан-Бәксәр авыл җирлеге транспорт инфраструктурасының мөһим состав өлеше булып тора. Алар җирлек территориясен күрше территорияләр белән бәйлиләр, җирлекнең торак пунктларын район үзәге белән бәйлиләр, җирлекнең барлык торак пунктларының тормыш эшчәнлеген тәэмин итәләр, җирлекне үстерү мөмкинлекләрен билгелиләр, алар буенча йөк ташу һәм пассажирлар йөртү башкарыла. Күпчелек очракта автомобиль юллары челтәрен үстерү дәрәҗәсенә җирлекнең тотрыклы икътисадый үсешенә ирешү бурычларын хәл итү, җирле җитештерүчеләрнең конкурентлык сәләтен күтәрү һәм халыкның тормыш

сыйфатын яхшырту бәйле.

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына авыл җирлегенең муниципаль милкендәге Алан-Бәксәр авыл җирлеге чикләрендә урнашкан муниципаль юллар, урам-юл челтәре һәм юл инфраструктурасы объектлары керә.

Алан-Бәксәр җирлеге икътисадын үстерү күбесенчә автомобиль транспортының эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге белән билгеләнә, ул гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юллары челтәрен үстерү дәрәҗәсенә һәм торышына бәйле.

Урам-юл челтәре гамәлдәге урамнар һәм юллар белән бәйләнештә проектланган. Торак территорияләрен иҗтимагый үзәкләр, җитештерү территорияләре белән бәйли һәм тышкы магистральләргә чыгуны тәэмин итә.

Урам-юл челтәре, урамнарның һәм юлларның функциональ билгеләнешен исәпкә алып, районның транспорт магистральләре челтәре белән үзара тоташ бербөтен система буларак формалаша. Челтәр структурасы муниципаль берәмлекнең гомуми планлаштыру структурасы һәм күләмнәре, аның ешлыгының үзара урнашуы белән билгеләнә.

Алан-Бәксәр авыл җирлегендә торак пунктлар һәм җирле һәм муниципальара әһәмияттәге юллар урамнарының бер өлеше канәгатьләнерлек хәлдә түгел.

Гәр авылына килү юлы (юлның гомуми озынлыгы 12 км), 5 км (V категория) - асфальт-бетон белән капланган, 7 км (IV категории) – вак таш белән каплаулы – тулы капиталь ремонт таләп итә.

Гәр авылыннан Шөмлән авылына бару юлы (озынлыгы 3,5 км) каты өслекле юл төзүне таләп итә.

Алан-Бәксәр авылы урам юллары:

каты өслексез:

Яңа ур. – 0,8 км,

Мәктәп ур. – 0,1 км,

Комлы ур. – 0,32 км,

Яшел ур. – 0,175 км.

Асфальт-бетон өслекле һәм чокырларны ремонтлауны таләп итә:

Үзәк ур. – 1,292 км,

Татарстан ур. – 0,2 км,

Мәктәп ур. – 0,101 км,

Кызыл Тау ур. – 0,3 км.

Алат спиртзавод авылы урам юллары:

каты өслексез:

Үзәк ур. – 0,6 км,

Яшьлек ур. – 0,6 км,

Завод ур. – 0,6 км,

Урман ур. – 0,1 км,

Болынлы ур. – 0,42 км.

Гәр авылы урам юллары:

каты өслексез:

Үзәк ур. – 0,5 км,

Мәктәп ур. – 0,25 км,

Урман ур. – 0,15 км,

Комбинат ур. – 0,2 км.

Әсән авылы урам юллары:

каты өслексез:

С.Сәйдәшев ур. – 0,65 км,

Ш.Усманов ур. – 0,3 км,

Ермаклы ур. – 0,35 км.

Шөмлән авылы урам юллары:

каты өслексез:

Үзәк ур. – 0,7 км.

Каты өслекле булмаган урам юлларында юл полотносына вак таш түшәү планлаштырыла.

Генераль план белән, Биектау муниципаль районының территориаль планлаштыру Схемасы чаралары нигезендә, Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә автомобиль юлларын үстерү буенча түбәндәге чаралар каралган:

- «Алан Бәксәр-Ислейтар урман хуҗалыгы» төбәк әһәмиятендәге юл участогына капиталь ремонт;

- «Алан Бәксәр - Ислейтар урман хуҗалыгы - Шөмлән» җирле әһәмиятле 10,3 км озынлыктагы юл участогын төзү;

- «Алат спиртзаводы - Путанай» җирле әһәмиятле юл участогын төзү.

Юл челтәрен үстерүнең җитәрлек дәрәҗәдә булмавы җирлек икътисадының һәм халкының шактый зур югалтуларына китерә, Алан-Бәксәр авыл җирлегенең социаль-икътисадый үсеше темпларын иң зур чикләүләреннән берсе булып тора, шуңа күрә җирлек өчен гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юллары челтәрен камилләштерү мөһим. Бу киләчәктә хезмәт ресурслары агымын тәэмин итәргә, җитештерүне үстерергә мөмкинлек бирәчәк, ә бу исә үз чиратында җирлекнең икътисадый үсешенә китерәчәк.

Автомобиль юллары табигый әйләнә-тирә мохит, кешенең хуҗалык эшчәнлеге һәм транспорт чараларының даими йогынтысына дучар ителә, нәтиҗәдә юлларның техник-эксплуатация торышы үзгәрә. Юллар челтәренең торышы аны карап тоту, ремонтлау һәм капиталь ремонт эшләрен вакытында башкару сыйфатына, тулылыгына һәм сыйфатына бәйле һәм чикләнгән күләмнәре шартларында финанс ресурсларын бүлүнең финанслау күләмнәренә һәм стратегиясенә турыдан-туры бәйле.

Юл комплексына инвестицияләр күләме җитәрлек булмаган шартларда, автомобильләштерү дәрәҗәсе үсеше юл челтәрен үстерү темпларыннан шактый алда бара, беренче планга юлларны карап тоту һәм эксплуатацияләү эшләре чыга. Агымдагы ремонтны башкарганда кул хезмәтен кыскартырга һәм башкарыла торган эшләрнең югары сыйфатын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә торган машина һәм механизмнарның махсуслаштырылган звеноларын кулланып, заманча технологияләр кулланыла. Шул ук вакытта агымдагы ремонт, капиталь ремонттан аермалы буларак, юл өслегенең сыйфатын күтәрүгә бәйле тигезлек, кытыршылык, ныклык характеристикалары һ.б. бурычларны хәл итми. Хәрәкәт ешлыгының даими үсүе шартларында, юл тармагын рәсми рәвештә теркәп җиткермәү транспорт

чараларының йөк күтәрүчәнлеген арттыру ягына хәрәкәт составының үзгәрүе ремонт арасы срокларны үтәмәүгә, ремонт ясарга вакыт җитмәгән участоклар санын туплауга китерә. Югарыда бәян ителгәннәрне исәпкә алып, чикләнгән финанс чаралары шартларында автомобиль юлларының һәм корылмаларның проблемалы участоклары санын мөмкин кадәр киметү максатында аларны оптималь файдалану бурычы тора.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын үстерүдә программалы-максатчан алым куллану финанс ресурслары чикләнгән шартларда юл тармагының кичектергесез проблемаларын хәл итүгә акчаларны системалы рәвештә җибәрергә мөмкинлек бирәчәк.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге бюджетында юл хуҗалыгына чыгымнарны финанслау җитмәү сәбәпле, аерым параметрлар буенча җирлек урамнарының шактый өлешенең эксплуатация торышы норматив документлар һәм техник регламентлар таләпләренә туры килми башлады.

Торак пунктлардагы урамнарда чокыр-чакырлар ремонтлау буенча шактый эш башкару зарурлыгына бәйле рәвештә урам-юл челтәрен карап тотуга матди чыгымнар артты.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясе буенча 18,2 км озынлыктагы региональ әһәмияттәге автомобиль юллары уза.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә урнашкан җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының озынлыгы 17,62 км тәшкил итә.

Төп җирле автомобиль юллары Алан-Бәксәр авыл җирлегенең урамнары һәм торак пунктларының аерым объектлары арасында бәйләү функцияләрен үти.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең автомобиль юлларында хәрәкәт ешлыгы югары түгел, ул 100-120 авт./сәг. тәшкил итә.

Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының үткәрү мөмкинлеге җитәрлек дәрәҗәдә.

Җирлекнең әйләнә-тирә мохитенә транспорт инфраструктурасының тискәре йогынтысының дәрәҗәсе зур түгел.

Кайбер участокларда юл өслегенең ныклыгы җитмәү зур кимчелек булып тора. Шулай ук Алан-Бәксәр авыл җирлеге урам-юл челтәрендә юл хәрәкәте иминлеге проблемасы булып тротуарларның фактта булмавы тора, бу авыл җирлегенең торак пунктларында җәяүле хәрәкәтне бик нык катлауландыра.

**1.5 Транспорт чаралары паркы составына һәм автомобильләштерү дәрәҗәсен, парковкалар (парковка урыннары) белән тәэмин итүне анализлау**

Алан-Бәксәр авыл җирлеген автомобильләштерү дәрәҗәсе 609 кешегә 174 автомобиль дәрәҗәсендә саклана.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә автотранспортны саклау җирлек халкының утар тирәсендәге кишәрлекләрендә гамәлгә ашырыла.

**1.6 Гомуми кулланылыштагы транспорт чараларының эшчәнлегенә, пассажир агымы анализын да кертеп, характеристика**

Пассажир транспорты халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә мөһим элемент булып тора, аннан башка җәмгыятьнең нормаль эшләве мөмкин түгел. Ул халыкның җитештерү, көнкүреш, мәдәни бәйләнешләр аркасында хәрәкәт итүгә булган

ихтыяҗларын канәгатьләндерергә тиеш. Пассажир транспорты предприятиеләр, оешмалар, мәдәни, спорт, көнкүреш һәм башка учреждениеләр кирә торган транспорт тарту үзәкләре арасында халыкны йөртү өчен билгеләнә.

Алан-Бәксәр авыл җирлеге территориясендә торак пунктлар эчендә җәмәгать пассажир транспорты хәрәкәте юк.

Җирлекнең административ үзәге - Алан-Бәксәр авылы буенча «Бикнарат ав. – Биектау ав.– Бикнарат ав.» автобус маршруты үтә.

**1.7 Җәяүлеләр һәм велосипед хәрәкәте шартларына характеристика**

Дөньядагы барлык иҗтимагый төркемнәрдә хәрәкәт итүнең төп һәм иң киң таралган төре. Асылда теләсә нинди маршрут җәяүле йөрү белән башлана һәм тәмамлана. Кайбер маршрутларда җәяү йөрү ерак походлар яки кибеткә кыска гына прогулка турында сүз баруына карамастан, хәрәкәт итүнең бердәнбер ысулы булып тора. Башка маршрутларда кеше җәяү бер яки берничә юл кисемтәсе узарга мөмкин - мәсәлән, җәяү автобус тукталышына кадәр һәм аннан автобуста барганда әлеге ике җәяүлеләр участогы арасында ниндидер ераклык булырга мөмкин.

Җәяүле хәрәкәт, нигездә, җәяүлеләр юлы (тротуарлар) буйлап бара, алар булмаган урыннарда - урамнарның узу урыннарында бара, бу юл-транспорт һәлакәтләре килеп чыгуга китерә. Шәхси торак төзелеше зонасында, шулай ук асфальт-бетон өслеге булмаган урыннарда җәяүлеләр хәрәкәте өчен тротуарлар җиһазланмаган.

Алан-Бәксәр авыл җирлегенең торак пунктларында җәяүлеләр хәрәкәтен оештыру проблемасы бар, чөнки алар түбән сыйфатлы яисә тротуарларның тулысынча булмавы белән бәйле.

Велосипед хәрәкәте, җәяүлеләр хәрәкәте кебек үк, шул ук өстенлекләргә ия, әмма ераграк дистанцияләргә күчеп йөрергә мөмкинлек бирә. Велосипедчыларның хәрәкәте гомуми файдаланудагы юллар буенча юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

